## САК БУЛЫЙК

Роберт Тимербаев көе
(Идрис Кәлимуллин репертуарыннан)

Гомерең юлында абынма.
Егылсаң, торуы бик авыр.
Үтәрләр кояшлы язларың,
Җәй үтәр, көз үтәр, кыш җитәр.
Хатамны төзәтәм дисәң дә,
Гомерләр узарлар, соң булыр!

*Кушымта:*
Хаталы көннәрдән, еллардан
Суынып бәгырьләр каталар.
Сак булыйк, һәр адым, һәр чакрым
Сагалап торалар хаталар!
Хаталар! Хаталар! Хаталар!

Күп вакыт ир башын җуядыр
Исәпсез эчелгән хәмерләр.
Күпмеләр кергәннәр, чыгалмас,
Чыгалмас салкын, тар кабердән.
Хәмергә сатылган гомерләр,
Гомерләр — кабынмас күмерләр.

*Кушымта.*

Гомерең юлында абынма
Киртәле булмасын ак юлың.
Син, җаным, кемнеңдер җан яры,
Әтисе кемнеңдер һәм улы.

Язмышлар хатасын төзәтеп
Бәхетле булуның тап юлын.

*Кушымта.*

Сак булыйк!

## ЯҢА ЙОРТ

Роберт Тимербаев көе
(Идрис Кәлимуллин репертуарыннан)

Яңа йортның нигезенә
Талир тәңкәләр салдык.
Ташып торсын монда муллык,
Бәхет, татулык, саулык.
Яңа йортлар котлы булсын,
Табыннары мул булсын.
Дус-туганга, җыр-моңнарга
Урын иң түрдән булсын!

*Кушымта:*

Яңа йорт – зур бәхет!
Чынга ашкан ак өмет.
Юмарт хуҗа, өстәл җыеп,
Өй түренә безне көт!
Яңа йорт – зур бәхет!
Чынга ашкан ак өмет.
Юмарт хуҗа, өстәл җыеп,
Өй туена безне көт!